РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.08.2024 с. Сарманово № 318

Сарман муниципаль районы милкендәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда сатып алына торган арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәткә түләүне кичектереп түләү срогын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы һәм «Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә Сарман муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Сарман муниципаль районы милкендәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда сатып алына торган арендалана торган мөлкәт өчен түләүне кичектереп түләү срогы күчемсез мөлкәт өчен биш ел һәм күчемле мөлкәт өчен өч ел тәшкил итә.

2. Арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәткә түләү тәртибен (бер үк вакытта яисә өлешләп) сайлау хокукы, шулай ук әлеге карарның 1 пункты нигезендә билгеләнгән чикләрдә өлешләп түләү сроклары арендалана торган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече яисә урта эшкуарлык субъектына карый.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TARSTAN.RU) игълан итәргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Сарман муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р.Р. Хөснимардановага йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе Ф.А.Вәлиев